# Аңлатма язуы

*Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,*

*Матурлыкны күреп тезләнәм.*

*Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген ,*

*Йә булмаса*

*Үзем үзгәрәм...*

**Разил Вәлиев**

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз. Ә ул үз чиратында, туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш. Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала.

**Разил Вәлиев** (тулы исеме **Разил Исмәгыйль улы Вәлиев**) — татар язучысы, шагыйрь, күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, Русиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Русия Гуманитар Фәннәр Академиясенең шәрәфле академигы.

Р. Вәлиев халык язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, туган мәдәниятебез, телебез, гореф-гадәтләребезне саклап калу һәм үстерү өчен тырыша.

Разил Вәлиев музеенда үткәрелгән очрашулар, экскурсия, дәресләр, татар әдәбиятенә , мәдәниятенә, сәясәтенә , тарихына кагылышлы материалларны өйрәтү аша балалар күңеленә патриотизм орлыклары салына. Мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр – укучыларга чын-чынлап илһам чыганагы.

“Р.Вәлиев иҗаты” музее (Тарих битләреннән) түгәрәге түбәндәге максаттан чыгып оештырыла:

– үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү;

– укучыларда эзләнү-тикшерену, материалны системага салу күнекмәләре формалаштыру;

– рухи һәм әхлакый , милли сафлыкка ия иҗади шәхес үстерү.

– шагыйрьләр , язучылар иҗаты, танылган татар шәхесләре белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

– укучыларның танып-белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү;
– үсеп килүче буынны мәктәп музее эшчәнлеге аша патриотлык һәм әхлакый яктан тәрбияләү;
– укучыларны татар шагыйрьләренең, язучыларның иҗатын өйрәнүгә җәлеп итү;
– укучыларда милли үзаң формалаштыру;
– музей фондын тулыландыру

Өстәмә белем бирү буенча бу программа 6 нчы класс укучылары өчен атнага 4,5 сәгать исәбеннән 140 сәгатькә, бер уку елына төзелде.

***Программаны тормышка ашыру юллары***

Музейда (түгәрәктә) татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте , тарихы , Р.Вәлиевнең иҗаты белән кызыксынган балалар шөгыльләнә. Программа үзенең эчтәлеге белән Разил Вәлиевнең тормышын , иҗатын һәм өлешчә татар әдәбиятын, мәдәниятын, тарихын үз эченә ала. Боларның барысын өйрәнү юллары һәм методлары төрле: семинар, экскурсия, очрашулар, , эзләнү– тикшеренү эшләре һ.б. Аларны үткәрү укучының яшеннән, әзерлек дәрәҗәсеннән, түгәрәк эшләренең максатыннан тора. Бигрәк тә экскурсияләр укучыларда зур кызыксыну уята. Укучыларның түгәрәк белән кызыксынулары артсын өчен, укытучы үткәрү формаларын чиратлаштырып барырга тиеш. Балалар мөстәкыйль рәвештә документаль чыганакларны өйрәнеп, тикшеренү эшләре алып барырга омтылалар. Тикшеренү эшләре укытучы җитәкчелегендә алып барыла. Эшне оештырган укытучы үзе дә, беренчедән, төп чыганакларны белергә тиеш. Икенчедән, үзе дә тикшеренү эше белән шөгыльләнергә, укучының эше белән кызыксынырга тиеш.

Бу прогамма укучыларга татар шагыйрьләре, язучылары , татар әдәбияты, тарихы, мәдәнияты турында тирәнрәк аңларга, төрле формадагы эзләнү эшләренә өйрәнергә мөмкинлек бирә. Программа буенча эшчәнлек нәтиҗәләре укучылар тарафыннан иҗади эшләр, реферат, презентацияләр һ.б. формасында тәкъдим ителә.

***Көтелгән нәтиҗәләр:***

“Разил Вәлиев иҗаты музее” (Тарих битләреннән...) түгәрәгендә шөгыльләнгән бала:

– татар шагыйрьләре, язучылары , татар әдәбияты, тарихы, мәдәниятына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;

– мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый,

– материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музеен тулыландыра;

– эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;

– уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;

– татар әдәбияты, театры, тарихы буенча белемнәрен арттыра;

– фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;

– үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;

– Р. Вәлиев кебек күпкырлы, шәхес татар тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле булган башка күренекле шәхесләре белән горурлана.

**Программаның эчтәлеге :**

1. Разил Вәлиевнең тормышы юлы
2. Разил Вәлиевнең иҗат юлы
3. Р.Вәлиевнең шигырьләре. (“Хыялый Мияубикә”, “Уенчыклар”, “Елаудан үзе туктады”, “Барысын да яратам”, “Йокла энем”, “Без кояш балалары”, “Кыш”, “Туган ягым”, “Ярата икән әни ”, “Тәрбияле малай”, “Минем сеңлем”, “Үпкәләгән”, “Кояш кебек” һ.б.
4. Р.Миңнуллин – балалар язучысы.
5. Р.Вәлиев –драматург.
6. Татар театры тарихы
7. Г.Камал театры артистлары
8. Т. Миңнуллин “Авыл эте Акбай”
9. Танылган татар шәхесләре . Марат Башаров, Чулпан Хаматова
10. Р.Вәлиев җырлар авторы.
11. Композитор Салих Сәйдәшев
12. Композитор Сара Садыйкова
13. Композитор Рөстәм Яхин
14. Танылган татар шәхесләре. Алсу Сафина
15. Рудольф Нуриев иҗаты
16. Борынгы Казан шәһәре.
17. Казан – спорт шәһәре.
18. Танылган шәхесләр. Гата Камский, Алисә Галләмова, Алия Мустафина
19. Герой –шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы.
20. М.Җәлил “Кызыл Ромашка ”
21. Р.Вәлиев – тәрҗемәче. А. Сент-Экзюпериның “Нәни принц” әсәре.
22. Р. Киплингның “Маугли” әсәре
23. Р.Вәлиев – тәрҗемәче.Әкиятләр “Алтын алма”
24. Р.Вәлиев – җәмәгать эшлеклесе.
25. Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты.